РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 ноября 2022 № 149

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы "Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Әтнә районы прокурорының 05.08.2022 № 02-08-02/Прдп 247-22 протестына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә районы Советының 2021 елның 04 октябрендәге 71 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм ТР Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (www.atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерү өчен).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының Җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы рәисе: Г.Г.Хәкимов